Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Фома авыл җирлеге Фома авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
КАРАР

«11» ноябрь 2020 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2020 елның 11 ноябрендә узган: «Сез 2021 елда Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Фома авыл җирлегенең Фома авылы территориясендә яшәүче балигъ булган, 1нче төркем инвалидлардан, балачактан инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан, көндезге формада белем алучы студентлардан кала, һәр кешедән 1000 сум сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә һәм алынган акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә ризамы?:

- торак пункт чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту һәм ремонтлау, шул исәптән сезонлы карап тоту һәм грунт - вак таш түшәү;

- су белән тәэмин итү чыганакларына норматив таләпләрне тәэмин итү буенча эшләр үткәрү» мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

җыенда катнашучы сайлау хокукына ия булган гражданнар исемлегенә 522 кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә 318 кеше катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 253 кеше тавыш бирде;

«ЮК» позициясе өчен җыенның 65 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Фома авыл җирлеге Фома авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. 2021 елда Нурлат муниципаль районының Фома авыл җирлеге Фома авылы территориясендә яшәү яшәүче 1нче төркем инвалидлардан, балачактан инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан кала, һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм әлеге акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкару буенча мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме?:

торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту һәм ремонтлау, шул исәптән сезонлы рәвештә карап тоту һәм грунт-вак таш түшәү; су белән тәэмин итү чыганакларына норматив таләпләрне тәэмин итү буенча эшләр башкару» мәсьәләсе буенча кабул ителгән карарны танырга.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Фома авыл җирлеге Фома авылы мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Фома авыл җирлеге тарафыннан кабул ителгән әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: Р.Х.Абдрахманов

Фома авыл җирлеге башлыгы Р.Х. Абдрахманов